**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Хокук мәсьәләләре буенча ведомствоара координация комитеты составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе һәм вазыйфалар атамалары үзгәрү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Хокук мәсьәләләре буенча ведомствоара координация комитетын оештыру турында» 2004 елның 19 июлендәге ПУ-490 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 26 декабрендәге ПУ-517 номерлы, 2007 елның 30 апрелендәге ПУ-218 номерлы, 2007 елның 18 декабрендәге ПУ-688 номерлы, 2008 елның 12 маендагы ПУ-206 номерлы, 2008 елның 26 декабрендәге ПУ-686 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-201 номерлы, 2009 елның 7 декабрендәге ПУ-649 номерлы, 2010 елның 15 февралендәге ПУ-69 номерлы, 2010 елның 16 сентябрендәге ПУ-617 номерлы, 2010 елның 30 декабрендәге ПУ-890 номерлы, 2011 елның 19 апрелендәге ПУ-222 номерлы, 2012 елның 29 июнендәге ПУ-519 номерлы, 2013 елның 2 мартындагы ПУ-183 номерлы, 2013 елның 19 сентябрендәге ПУ-915 номерлы, 2013 елның 11 декабрендәге ПУ-1211 номерлы, 2014 елның 25 гыйнварындагы ПУ-47 номерлы, 2015 елның 20 февралендәге ПУ-179 номерлы, 2015 елның 8 маендагы ПУ-430 номерлы, 2015 елның 10 ноябрендәге ПУ-1086 номерлы, 2016 елның 17 ноябрендәге ПУ-1016 номерлы, 2017 елның 14 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы, 2017 елның 10 августындагы ПУ-664 номерлы, 2018 елның 26 мартындагы ПУ-269 номерлы, 2018 елның 14 сентябрендәге ПУ-638 номерлы, 2018 елның 13 октябрендәге ПУ-728 номерлы һәм 2019 елның 4 мартындагы ПУ-155 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Хокук мәсьәләләре буенча ведомствоара координация комитеты (алга таба – Комитет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комитет составыннан Т.Д. Нагумановны, А.А. Фоминны чыгарырга;

б) Комитет составына Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызын – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча) кертергә;

в) Комитет әгъзасы Г.И. Сергееваның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Бизнес коррупциягә каршы» иҗтимагый процедуралар үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасының административ һәм гражданлык юнәлешләре буенча рәистәше (килешү буенча).

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 10 февраль
№ ПУ-72